**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«26 » декабрь 2022 ел　　　　Яр Чаллы　　　　№ 4208

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1287 номерлы, 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карарлары нигезендә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм хезмәткә түләүне тәртипкә салу максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне бергә башкарган, хезмәт күрсәтү зоналары киңәйгән һәм үзенең төп эше белән берләттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын башкарган өчен өстәмә түләүләр дә кертелә;

аерым оешмалар эшчеләренең эш хакы айлык тариф ставкасыннан, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәмнән, матди ярдәмнән, машина йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмә түләүдән, һөнәрләрне бергә башкарган, хезмәт күрсәтү зоналары киңәйгән һәм үзенең төп эше белән берләттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең бурычларын башкарган өчен айлык өстәмәләрдән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора;

аерым оешма җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаре вазыйфаи окладлары күләмендә исәпләнә, ул 11 958 сум тәшкил итә;

аерым учреждениеләр хезмәткәрләренең айлык тариф ставкалары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешма җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентларын 1, 2 кушымталар нигезендә;

аерым оешмаларның эшчеләре хезмәтенә түләү разрядлары диапазонын 3 кушымта нигезендә.

3. Аерым оешма җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәне түбәндәге күләмнәрдә:

| эш стажы белән | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15; |

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә вазыйфаи окладка айлык өстәмәне;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләүне;

4) билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) еллык түләүле отпуск биргәндә елга вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләүне.

Җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә календарь ел дәвамында түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр бирелә торган түләү декабрьдә хезмәткәр гаризасы буенча эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә беренче ел эшләгәндә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы эшкә кергән көннән календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

6) ике вазыйфаи оклад күләмендә матди ярдәм.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә һөнәрләрне бергә башкарган, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйгән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча

булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын башкарган өчен өстәмә түләүне вазыйфаи окладның 50 процентына кадәр, билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә билгеләргә.

5. Аерым оешмалар эшчеләренә билгеләргә:

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмәне, хезмәт җиңел автомобильләрне йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш көне өчен өстәмәләр кертүне исәпкә алмыйча, айлык тариф ставкасының 8 процентына кадәр күләмдә;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләрне (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер айлык тариф ставкасы күләмендә матди ярдәмне.

Эшчегә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм декабрьдә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Эшчегә беренче ел эшләгәндә еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәмне түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы эшкә кергән көннән календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә матди ярдәмне;

5) хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмәне түбәндәге күләмнәрдә:

I класс машина йөртүчеләргә – 5 процент,

II класс машина йөртүчеләргә – 2 процент,

машина йөртүче сыйфатында эшләгән өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасыннан;

6) һөнәрләрнебергә башкарган, хезмәт күрсәтү зоналары киңәйгән һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең бурычларын үтәгән өчен өстәмә түләүләр - билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә гамәлдәге законнар нигезендә төп эш буенча айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр;

төнге вакытта эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) – хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгәнчә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен – икеләтә көндезге тариф ставкасы күләмендә;

хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш көне өчен - айлык тариф ставкасының 10 проценты күләмендә.

6. Хезмәткәрләргә тиешле федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарырга.

7. Аерым оешмаларның җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә вазыйфаи окладларны түләү өчен юнәлтелә торган средстволар суммасыннан артык хезмәткә түләү фондын формалаштырганда, түләү өчен түбәндәге средстволар карала дип билгеләргә (бер елга 12 вазыйфаи окладтан чыгып исәпләгәндә):

1) тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә – вазыйфаи окладларның җиде проценты күләмендә;
2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;
3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр – вазыйфаи окладларның бер проценты күләмендә;
4) айлык акчалата бүләкләү – вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә;
5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү һәм вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә матди ярдәм.

8. Аерым оешмаларның эшчеләренә тариф ставкаларын түләү өчен юнәлтелә торган хезмәткә түләү фондын формалаштырганда, түләү өчен түбәндәге средстволар карала дип билгеләргә (бер елга исәпләгәндә):
1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә – бер айлык тариф ставкасы күләмендә;
2) класс өчен машина йөртүчеләргә айлык өстәмә; нормалаштырылмаган эш көне өчен - айлык тариф ставкасының бер бөтен уннан сигезе күләмендә;
3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр – бер айлык тариф ставкасы күләмендә;
4) еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм – бер айлык тариф ставкасы күләмендә, айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып.

9. Билгеләргә:

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме тулаем сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш;

аерым оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладларын арттыру муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру өчен каралган күләмнәрдә һәм срокларда гамәлгә ашырыла;

аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең охшаш категорияләрендәге хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру өчен каралган күләмнәрдә һәм срокларда гамәлгә ашырыла;

әлеге карар кабул ителү белән, аерым оешма хезмәткәрләренә түләүнең башка шартлары кулланылмый.

10. «Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

11. Аерым оешмалар җитәкчеләренә:

хезмәткәрләр вазыйфаларының исемен әлеге карарның 1 кушымтасына;

аерым оешма хезмәткәрләренең өстәмәләрен һәм башка түләүләрен билгеләү турында элек бастырылган актларны әлеге карарга туры китерергә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешма җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәплэгәндә кулланыла торган III группа коэффициентларын 1 кушымта нигезендә кулланырга;

12. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук

мөнәсәбәтләренә кагыла.

13. Әлеге норматив акт үз көченә кергән көннән Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 15 маендагы 1876 номерлы карары (кертелгән барлык үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

14. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

15. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның ________ ______________________ ______ номерлы карарына 1 кушымта

# Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары

| Вазыйфа исеме | Коэффициент | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | I төркем | II төркем | III төркем | IV төркем | V төркем |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 1,55 | 1,55 | 1,36 | 1,34 | 1,34 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 1,34 | 1,34 | 1,32 | 1,30 | 1,30 |
| Бүлек башлыгы | 1,30 | 1,30 | 1,27 | 1,25 | 1,25 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,23 | 1,23 | 1,21 | 1,19 | 1,17 |
| Сектор башлыгы | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 |
| Баш белгеч | 1,17 | 1,17 | 1,15 | 1,12 | 1,10 |
| Әйдәүче белгеч | 1,10 | 1,10 | 1,09 | 1,07 | 1,05 |
| I категорияле белгеч | 1,03 | 1,03 | 1,02 | 1,01 | 1,00 |
| II категорияле белгеч | 1,02 | 1,02 | 1,01 | 1,00 | 1,00 |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның _______ ______________________ _____ номерлы карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә структур бүлекчәләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары

| Вазыйфа исеме | Коэффициент |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинада язу бюросы мөдире, күчермә-күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш кәгазьләре белән эшләүче , архивариус, стенографистка, секретарь-стенографистка, машинистка, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкче секретаре | 1,0 |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның _______ ______________________ _____ номерлы карарына 3 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым бюджет өлкәсе оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләр хезмәтенә түләү разрядлары диапазоны

| Һөнәр исеме | Хезмәткә түләү разряды |
|---|---|
| Гардеробчы, официант, курьер | 1 |
| Сакчы (вахтер), җитештерүһәм хезмәт биналарын җыештыручы, лифтчы, келәтче, йөкче | 1 - 2 |
| Электрон исәпләү һәм исәпләү машиналары операторы, биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшчесе | 2 - 4 |
| Күчермә һәм күбәйтү машиналары операторы | 2 - 3 |
| Җиңел автомобиль йөртүче | 4 - 5 |

Искәрмә.

Җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручыларга 2 разрядлы тариф ставкасы җитештерү биналарын, шул исәптән җитештерү калдыкларын, санузелларны һәм җәмәгать бәдрәфләрен җыештыру эшләрен башкарганда билгеләнә.

Машина йөртүчеләргә 5 разрядлы тариф ставкасы ике - өч типтагы җиңел автомобильләрдә эшләгәндә, шулай ук, автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү махсуслаштырылган хезмәте булмаган очракта, автомобильгә ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү буенча бөтен эшләр комплексын башкарганда билгеләнә.